Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк
авыл җирлегенең Ялтау торак пунктында
гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлегенең Ялтау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Ялтау авылында Тынычлык урамында юлларны ремонтлау»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 йорт; Ялтау авылы, Нагорная урамы, 38 йорт; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов